

Виолетта Камиль кызы Арикованын хезмәт коне иртән тугызынчы яртыда башлана. Бу официаль. Әмма еш кына иртәрәк башланып карангы кичкә кадәр дә дәвам итә анын хезмәт коне. Ләмберә муниципаль районы мәгарифе белән мәдәнияты учреждениеләренә хезмәт кvрсәтv Үзәгендә эш житәрлек; директор кешегә жаваплылык та остәлә. - Без егерме дvрт оешмага хезмәт кvрсәтәбез: тулы бухгалтерлар исап-хисабын алып барабыз һәм олешчә хезмәтне дә кvрсәтәбез, - дип район гәжите корреспондентына сойләгән Виолетта Камиль кызы. – Зарплата, чыгым белән керем хисаплары һәм башка эш торләрен башкарабыз. Хезмәт штаты да кечкенә тvгел – унбиш хезмәткәр, әмма эш барысына житәрлек.      Инвентаризация барган чакта, яки планлаштырылган мәсьәләләрне башкарганда, оешмаларга vзләренә чыгып килергә туры килә. Эшебезнен спецификасы бу, vзем сайладым…

Чыннан да, экономистлар, бухгалтерлар эше авыр, Виолетта Арикова моны Н.П.Огарев исемендәге МГУнын экономия факультетынын бишенче курсында Ләмберә мәгариф Идарәсендә практика vткәндә ачыктан-ачык анлый. Әмма авырлыклар аны куркытмый. Саннарны ярата ул. Вузны тәмамлагач, Үзәктә хезмәт биографиясен башлап жибәрә язма героебыз.

Исап-хисапчылар профессиясе, бер карашка, бик ук кызыклы дип әйтvчеләр аз. Кызыклы дип санаучылар да байтак. Виолетта Камиль кызы Арикованын һонәре турында фикере тvбәндә.

- Беренче карашка экономист яки бухгалтер хезмәте «коры» һәм кызыксыз, дип кvренә: цифрлар һәм тагы бер тапкыр цифрлар, кәгазь тавы, отчетлар һәм расчетлар... Мин алай тvгел дип уйлыйм, югарыда санап киткән профессиямнен кызыклы vзенчәлеге нәкъ менә шунда. Мин сайлаган хезмәтемне яратам һәм нәкъ аны сайлаганга бер дә vкенмим. Профессиядә кешеләр һәрвакыт булырга тиеш: кvп укып, кvпне белергә тиешле эшчеләр без. Үз остендә эшләv дә шәхси вакытынны ала. Еш vзенне нәрсәдәдер чиклисен, - ди Виолетта Камилевна. - Мәсәлән, китап укырга бик яратам мин, ә кvп вакыт матур әдәбият әсәрләре уку урынына норматив документларны ойрәнергә туры килә - ансыз беркая бара алмыйсын, чонки һәр кон нәрсәдер vзгәрә; vзгәрешләр кvп, аларны белергә тиешмен. Шуна барысына да житешергә тырышам. Гаиләмә дә вакыт табам мин. Улым бишенче сыйныфта укый, ана ярдәм итәм һәм башка ой эшләрен эшләргә туры килә. Хатын-кыз тырыша инде ул.

Гаилә - ул гаилә инде, ансыз тормыш ямьсез. Тормышым матур, vземне бәхетле  дип хис итәм: кызыклы эшем - хисап эшен дорес сайлаганмын мин, якын кешеләрем мине анлый,

кирәк чакта ярдәм итә.
Югары бәяләнә торган сыйфатларга ия ул Виолетта Камиль кызы: бик тәртипле, тыйнак, дореслек ягында тора торган кеше. Анын белән эшләргә дә, кинәшләшергә дә, уртак тел, фикер табарга да була. Гаиләсе белән пар канат булып озын-озак бәхетле гомер юлын vтсеннәр.

**Н.Хәлил**